ГЛАВА
СТАРОЧУКАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧОКАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

Иске Чокалы авылы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 сентябрь 2023ел № 11

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренең коррупциягә каршы үз-үзен тотышы стандартына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 23 октябрендәге 11 номерлы карары(07.06.2018 ел № 13, 17.10.2018 ел №24 редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренең коррупциягә каршы үз-үзен тотышы стандартына» түбәндәге үзгәрешне кертергә:

**3.1 пунктның 3 абзацын түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләргә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, мондый белешмәләрне мәҗбүри тапшырганда, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган белешмәләр тапшыру йә белә торып дөрес булмаган белешмәләрне муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Чокалы авыл җирлеге
башлыгы: Р.Р.Низамутдинов